**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 октябрендәге 4374 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 9 июлендәге 4498 номерлы «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү методикасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль законны, Казан шәһәре Думасының 2011 елның 17 июнендәге 19-6 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге һәм бу хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү билгеләү тәртибе турында»гы карарын гамәлгә ашыру максатыннан, Казан шәһәре Думасының 2024 елның 26 июнендәге 18-30 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 24-3 номерлы «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе” муниципаль казна учреждениесе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 9 июлендәге 4498 номерлы «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү методикасын раслау турында»гы карарына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 2 февралендәге 286 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 9 июлендәге 4498 номерлы карары кушымтасы дип санарга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 25 июлендәге 5121 номерлы «“Түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында

белешмә бирү” хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен раслау хакында»гы, 2021 елның 28 декабрендәге 3491 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 25 июлендәге 5121 номерлы «“Түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү” хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен раслау хакында»гы» карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 октябрендәге
4374 номерлы карарына
кушымта

**«Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләүне билгеләү методикасы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләүне билгеләү методикасы (алга таба – Методика) хосусыйлаштырылган торакның барлыгы (юклыгы) турында белешмә бирү буенча кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткән өчен (алга таба – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү) түләү күләмен билгеләү тәртибен билгели.

1.2. Методика Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткәндә куллану өчен билгеләнгән.

1.3. Әлеге Методиканың максаты – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүне оештыру өчен кирәкле чыгымнарның икътисади яктан нигезләнгән күләмен билгеләү.

1.4. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү гариза бирүче акчалары хисабына башкарыла.

1.5. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткән өчен түләү күләме исәп-норматив чыгымнардан һәм аны күрсәтүгә икътисади яктан нигезләнгән чыгымнардан чыгып билгеләнә.

## II. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтне күрсәтүнең төп принциплары

2.1. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтне күрсәткән өчен түләү күләме чыгымнарның үз-үзен аклавы принцибыннан чыгып билгеләнә.

2.2. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткән өчен түләү әлеге Методикада билгеләнгән иң чик күләмнән артып китә алмый.

## III. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү

3.1. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүгә икътисади яктан нигезләнгән чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Nэ = (Nотс x n) + Оот + Nрм + Nси + Nн, монда:

Nотс – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнар һәм аның хезмәте өчен түләү чыгымнарына өстәп исәпләнгән сумма;

n – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр саны;

Оот – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең еллары резервына чыгымнар исәбе;

Nрм – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү өчен турыдан-туры кулланыла торган чыгым материалларына уртача планлаштырыла торган чыгымнар;

Nси – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүгә бәйле коммуналь хезмәтләргә чыгымнар;

Nн – гомуми хуҗалык чыгымнары.

3.2. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнар һәм аның хезмәт хакы буенча түләүләргә өстәп исәпләнә торган сумма түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Nотс = Тс x Vт + НОТ, монда:

Тс – хезмәткәрнең Методиканың 1 номерлы кушымтасында күрсәтелгән исәп-норматив чыгымнардан чыгып билгеләнә торган уртача бер сәгатьлек хезмәт хакы;

Vт – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтне күрсәтүгә кирәкле вакыт күләме (Методиканың 2 номерлы кушымтасы);

НОТ – Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә хезмәткәрнең хезмәт хакы буенча түләүләргә өстәп исәпләнә торган суммалар.

3.3. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү өчен турыдан-туры кулланыла торган чыгым материалларына уртача планлаштырылган чыгымнар (Nрм)

Методиканың 3 номерлы кушымтасында күрсәтелгән чыгымнар сметасы нигезендә билгеләнә.

3.4. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүгә бәйле коммуналь хезмәтләргә чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Nси = (Рси /р /12 ай), монда:

Рси – кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вәкаләтле орган өчен расланган коммуналь хезмәтләрдән файдалануның еллык күләме;

р – вәкаләтле орган хезмәткәрләре саны.

Коммуналь хезмәтләргә чыгымнарны исәпләү Методиканың 4 номерлы кушымтасында китерелгән.

3.5. Гомуми хуҗалык чыгымнары (Nн) Nотс, Опр, Nрм статьялары буенча чыгымнар суммасының 10 процентыннан арта алмый.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәткән өчен түләү күләме елына кимендә 1 тапкыр һәм чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча яңадан карала.

___________________________

«Бушлай хосусыйлаштыру
хокукыннан файдалану
турында белешмә бирү»
хезмәтен күрсәткән өчен
түләү күләмен исәпләүне
билгеләү методикасына
1 номерлы кушымта

**«Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтен күрсәтүгә исәп-норматив чыгымнар (Тс)**

| № т/б | Норматив исеме | Сан характеристикалары (сумнарда) | Исәп-норматив чыгымнарны нигезләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәткәрнең уртача бер сәгатьлек хезмәт хакы (Тс) | 388,82 | Штат расписаниесе нигезендә хезмәткәрнең уртача эш хакы күләме |

«Бушлай хосусыйлаштыру
хокукыннан файдалану
турында белешмә бирү»
хезмәтен күрсәткән өчен
түләү күләмен исәпләүне
билгеләү методикасына
2 номерлы кушымта

**Сарыф ителгән эш вакытының хронометражы нигезендә «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтен күрсәтүгә кирәкле вакыт күләме (Vт)**

| № т/б | Операциянең исеме | Хезмәт сыешлыгы, бер сәгатькә |
|---|---|---|
| 1 | «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» (Vт) | 0,25 (яки 15 мин) |

«Бушлай хосусыйлаштыру
хокукыннан файдалану
турында белешмә бирү»
хезмәтен күрсәткән өчен
түләү күләмен исәпләүне
билгеләү методикасына
3 номерлы кушымта

**Матди запасларга уртача планлаштырылган чыгымнар (Nрм)**

| **№ т/б** | **Чыгым статьяларының атамалары** | **«Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү», сумнарда** |
|---|---|---|
| 1 | Чыгым материалларына чыгымнар (Nрм) | |
| | Канцелярия товарлары (тизберкеткечләр, аркалы механизмлы папка-регистраторлар, кәгазь, файллар, ручкалар, карандашлар, файллар, конвертлар, картриджны алмаштыру һәм аңа буяу тутыру), элемтә хезмәтләре, программа белән тәэмин итү | 6,85 |

«Бушлай хосусыйлаштыру
хокукыннан файдалану
турында белешмә бирү»
хезмәтен күрсәткән өчен
түләү күләмен исәпләүне
билгеләү методикасына
4 номерлы кушымта

**Коммуналь хезмәтләргә чыгымнар (Nси)**

| **№ т/б** | **Чыгым статьяларының атамалары** | **«Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү», сумнарда** |
|---|---|---|
| 1 | Коммуналь хезмәтләргә чыгымнар (Nрм) | |
| | Су белән тәэмин итү, су чыгару, җылылык белән тәэмин итү, электр энергиясе | 5,44 |

«Бушлай хосусыйлаштыру
хокукыннан файдалану
турында белешмә бирү»
хезмәтен күрсәткән өчен
түләү күләмен исәпләүне
билгеләү методикасына
5 номерлы кушымта

**«Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтен күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмнәре**

1. Хезмәт хакы буенча чыгымнарны һәм түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә рәсмиләштерү өчен җаваплы хезмәткәрнең хезмәт хакы буенча түләүләргә өстәп исәпләнә торган сумманы исәпләү:

Nотс = Тс х Vт + НОТ = 388,82 сум/сәг. х 0,25 + 29,36 сум = 126,57 сум.

**Хезмәткәрнең бер сәгатькә уртача эш хакын исәпләү (Тс)**

| № т/б | Чыгым статьяларының атамалары | «Бушлай хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү», сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Хезмәт өчен түләү<br>(хосусыйлаштыру бүлеге – баш белгеч) | |
| 1.1 | Уртача хезмәт хакын исәпләү | |
| | - хезмәт хакы | 23 448,00 |
| | - айлык өстәмә түләүләр | 13 834,82 |
| | - стимуллаштыру түләүләре | 19 883,90 |
| | **Барлыгы** | **57 166,72** |
| | Айга уртача түләүләр – 57 166,72;<br>бер айга уртача эш көннәре – 20,42 | 2 799,52 |
| | Уртача бер сәгатьлек хезмәт хакы: сәгатенә 2 799,52/7,2 | 388,82 |

НОТ – Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәткәргә хезмәт өчен түләүгә өстәп исәпләнә торган суммалар 30,2% тәшкил итә.

НОТ=(Тс х Vт) х 30,2%.

НОТ = (388,82 х 0,25) х 30,2%= 29,36 сум.

2. Отпусклар резервына чыгымнарны исәпләү (Оот):

55 000,00 сум/245 көн/7,2 сәг. х 0,25 = 7,79 сум.

3. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры файдаланыла торган матди запасларга смета нигезендә расланган чыгымнарны (Nрм) исәпләү:

1 836 938 сум/38 кеше/245 көн/7,2 сәг. х 0,25 = 6,85 сум.

4. Вәкаләтле орган тарафыннан коммуналь хезмәтләр куллануның расланган еллык күләме нигезендә коммуналь хезмәтләргә чыгымнарны исәпләү (Nси):

1 458 900 сум/38 кеше/12 ай = 1 хезмәткәргә аена 3 199,34 сум;

3 199,34 сум/20,42 көн/7,2 сәг. х 0,25 = 5,44 сум.

5. «Түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтен күрсәткәндә гомумхуҗалык чыгымнарын (Nн) исәпләү:

(126,57 сум + 7,79 сум + 6,85 сум) х 10% = 14,12 сум

6. «Түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану турында белешмә бирү» дигән 1 (бер) хезмәтне рәсмиләштерү бәясенең иң чик күләме:

126,57 + 7,79 + 6,85 + 5,44 + 14,12 = 160,77 сум.